**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_09__» ____11____ 2023 ел.** **№ __294___**

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 05 октябрендәге 291 номерлы «Татастан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалар билгеләү турында һәм хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, күрсәтелгән актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә карата таләпләрне раслау турында» карарына үзгәрешләрләр кертү хакында (20.05.2019 №107; 26.03.2021 №67 карарлар редакциясендә)

“Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 4 өлешенең 1 пунктына таянып, гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 18 маендагы 476 номерлы “Сатып алулар өлкәсендә нормалар билгеләү, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә гомуми таләпләрне раслау турында” карарын үтәү йөзеннән, карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 05 октябрендәге 291 номерлы «Татастан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалар билгеләү турында һәм хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, күрсәтелгән актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә карата таләпләрне раслау турында» карарына (20.05.2019 №107; 26.03.2021 №67 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә таләпләрне раслау хакында» карарының 1 нче кушымтасын, 1 нче кушымта нигезендә, яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов

Азнакай муниципаль районы
Башкарма комитет карарына
1 нче кушымта
«____» _________ 2023 № _____

Татастан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалар билгеләү турында һәм хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, күрсәтелгән актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә карата таләпләр

1. Әлеге документ «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, «Сатып алулар өлкәсендә, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә гомуми таләпләрне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 18 маендагы 476 номерлы карары нигезендә (алга таба - 476 номерлы Карар) эшләнгән, хокукый актларны эшләү һәм кабул итү тәртибенә, эчтәлегенә, үтәүне тәэмин итүгә таләпләрне (алга таба - Таләпләр) билгели:

а) Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының:

- сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә таләпләр;

- сатып алына торган муниципаль органнар һәм күрсәтелгән органнар карамагындагы казна учреждениеләре, бюджет учреждениеләре һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының унитар предприятиеләре тарафыннан аерым товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр төрләре (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләре) таләпләрен билгеләү кагыйдәләре;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль органнары (шул исәптән ведомство буйсынуындагы казна учреждениеләре) функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләре;

б) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль органнарының:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль органнары (шул исәптән ведомство буйсынуындагы казна учреждениеләре) функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнар;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының алар сатып ала торган һәм күрсәтелгән органнар буйсынуындагы казна учреждениеләре, бюджет учреждениеләре һәм унитар предприятиеләре тарафыннан аерым товарлар, эшләр, хезмәтләр (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләре) төрләренә карата таләпләр.

2. Әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы “а” пунктчасында күрсәтелгән хокукый актлар Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының карар проектлары рәвешендә эшләнә.

3. Муниципаль органнар әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында һәм 1 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацында муниципаль органнар каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында күрсәтелгән хокукый актлар проектлары (алга таба - иҗтимагый советлар) алдан фикер алышырга

хокуклы.

4. Заказ бирүчеләр сатып ала торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләренә) таләпләрне билгеләүнең гомуми кагыйдәләрен үтәп түбәндәгеләрне үтәргә тиешләр:

а) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләре исемлеген (алга таба - исемлек) төзү һәм раслау тәртибен, аларның кулланучылар үзлекләренә (шул исәптән сыйфат характеристикаларына) һәм башка характеристикаларга (шул исәптән иң чик бәяләрне) таләпләр билгели торган муниципаль органнар түбәндәгеләрне билгели:

- исемлеккә кертелә торган мәгълүмат составын;

- исемлекне төзегәндә икътисадый эшчәнлек төрләре буенча Гомумроссия продукция классификаторын куллануны;

- сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең сатып алу үзенчәлекләрен (шул исәптән сыйфат характеристикаларын) һәм башка характеристикаларын сайлау тәртибе, аларга карата норматив күрсәткечләр билгеләү таләп ителүне;

- сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең куллану үзенчәлекләрен (шул исәптән сыйфат характеристикаларын) һәм башка характеристикаларын (шул исәптән иң чик бәяләрен) характерлый торган күрсәткечләрне билгеләүгә таләпләрне;

- исемлеккә кертү өчен товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләрен сайлап алганда кулланыла торган критерийларны;

б) исемлекнең якынча формасын.

5. Муниципаль органнар (казна буйсынуындагы учреждениеләрне дә кертеп) функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләүнең гомуми кагыйдәләре түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуга бәйле чыгымнарны классификацияләү;

б) муниципаль органнар (тиешле буйсынуындагы казна учреждениеләрен дә кертеп) функцияләрен тәэмин итүгә чыгымнарны исәпләү тәртибен билгеләү шартларын;

в) күрсәтелгән органнарның һәм учреждениеләрнең төп хезмәткәрләре саны күрсәткечен билгеләү тәртибе.

6. Әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының хокукый актлары «а» пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацларында һәм әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «в» пунктчасының икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән актларны әзерләү һәм кабул итү тәртибенә карата таләпләр, күрсәтелгән актларны карап тотуга таләпләр, шул исәптән:

а) күрсәтелгән актларны хокукый рәвешкә, килештерү тәртибенә һәм сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында раслау һәм урнаштыру срокларына карата таләпләр;

б) күрсәтелгән актларга үзгәрешләр кертү очраклары;

в) җәмәгать контролен гамәлгә ашыру максатларында күрсәтелгән актлар буенча мәҗбүри фикер алышу таләбе, шулай ук мондый фикер алышу тәртибе.

7. Сатып алулар өлкәсендә, дәүләт (муниципаль) финанс контроле өлкәсендә тикшереп торуны һәм мониторингны гамәлгә ашыруны җайга сала торган закон чыгару һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә сатып алулар өлкәсендә контроль һәм мониторинг барышында заказчылар тарафыннан әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән хокукый актлар нигезләмәләренең үтәлешен тикшерә.